Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының
Кадер авыл җирлеге Советы

КАРАР

14.08.2020 № 210

"Физик затлар милкәтенә салым турында"
2014 елның 14 ноябрендәге 150 номерлы
Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге
Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. "Физик затлар милкәтенә салым турында" 2014 елның 14 ноябрендәге 150 номерлы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советы карарына (2015 елның 11 сентябрендәге 194 номерлы, 2018 елның 30 октябрендәге 146 номерлы, 2019 елның 22 апрелендәге 169 номерлы, 2019 елның 18 ноябрендәге 194 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктның 1 пунктчасының өченче абзацында «бирелгән» сүзен һәм «дача» сүзен төшереп калдырырга.

2. Карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**Кадер авыл җирлеге**
**башлыгы** **Р.М. Нуруллин**